# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# БЕЛОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 14 11.01. 2016 ел

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советы:

1.Җирле референдум үткәрү инициативасы:

«Сез 2016 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә урнашкан, шулай ук теркәлмәгән, әмма җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан Беловка авыл җирлеге территориясендә яшәүче яки милеккә ия булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын еллык бер тапкыр түләүне кертүгә ризамы 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм студентлар, көндезге уку формасы буенча укучылар алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтәләр:

Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту

- .Яңа Үзи авылы зиратының коймасын алыштыру

Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

1. Яңа Үзи торак пунктында вак таш белән капланган юлларны ремонтлау Родниковая урамы, Үзәк урамы, Бакча урамы; Беловка авылы, Ленин урамы, Шәлеби урамы; Алексеевка авылы, Үзәк урамы; Федоровка авылы, Үзәк урамы; Сергеевский Бистәсе, Горький урамы.

ӘЙЕ ЮК

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге Советы рәисе: И.Р.Махмутов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
р06-640/13
СОВЕТ БЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1603000732 ОГРН 1021605554990